| СОВЕТ<br>НИЖНЕЧЕКУРСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТҮБӘН ЧӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Нижнее Чекурское

19.02.2026 ел № 9/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының
Түбән Чәке авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы
нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Түбән Чәке авыл җирлеге Советы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.12.2025 ел, № 505-ФЗ Федераль закон нигезендә карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Советының 31.05.2023 ел, №31/1 карары белән расланган Чүпрәле муниципаль районының Түбән Чәке авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (27.07.2023 № 32/2, 18.12.2023 № 38/5, 23.05.2024 № 42/2, 13.12.2024 № 47/2 редакциясендә), 13 статьяның 3 пунктындагы 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"8) әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда «коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр. Күрсәтелгән белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан «коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм форма буенча тапшырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми басылып чыгу мизгеленнән үз көченә керә.

Түбән Чәке авыл
җирлеге Башлыгы А.В. Солдатов